ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.02.2017 Балык Бистәсе штп. № 16пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының, баш бухгалтерларының һәм шундый муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы нисбәтенең иң чик дәрәҗәсе турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү, премияләү күләмнәре турында нигезләмәләрне раслау хакында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы түләүне тәртипкә салу һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүне стимуллаштыру максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 145 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында" 12.03.2015 №148 карарының нигезләмәләрен, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренә (генераль директорларына), аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына хезмәт хакы түләү һәм премия бирү күләмнәре турында нигезләмәләрне раслау хакында» 09.06.2015 №1-п , "Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләренең баш бухгалтерлары һәм әлеге предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы һәм хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәм Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре җитәкчеләренә (генераль директорларына), аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына премия бирү турындагы

нигезләмәләргә үзгәрешләр кертү хакында»27.12.2016 №5-п карарларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 46 статьясы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Гамәлгә куючы вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты башкара торган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының һәм мондый муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең (җитәкченең, аның урынбасарларының, баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) уртача айлык эш хакы нисбәтен 1дән 8 тапкырга кадәр билгеләргә.

2.Расларга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында нигезләмәне;

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын премияләү турында нигезләмәне.

3.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре белән хезмәт килешүләре төзегәндә әлеге карар белән расланган нигезләмәләргә таянып эш итәргә.

4.Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренә квартал саен, җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм муниципаль унитар предприятиеләрнең баш бухгалтерларының һәм муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакы (җитәкчеләрнең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) нисбәтенә анализ оештырырга һәм әлеге анализ нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләнгәнформа буенча отчет кварталыннан соң килгән айның 15 числосын кадәр тапшырырга.

5.Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләренең әлеге карарның 4 пункты нигезендә бирелгән мәгълүматның тулылыгы һәм дөреслеге өчен шәхси җаваплылыгын билгеләргә.

6.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренә, аларның урынбасарларына һәм баш бухгалтерларына хезмәт хакы түләү һәм премия бирү күләмнәре турында нигезләмәләрне раслау хакында»29.08.2016 ел, №141пи карарын үз көчен югалткан дип таныргa

7. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы

буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

8.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Д. Х. Гатиятовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 1 февралендәге 16 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү күләмнәрен билгеләү турында нигезләмә**

**I.Гомуми нигезләмәләр**

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт өчен түләү күләмнәрен билгеләү турындагы әлеге нигезләмә (алга таба-нигезләмә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакын камилләштерү, муниципаль унитар предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлегенең ахыргы нәтиҗәләренең муниципаль унитар предприятиеләрнең (алга таба – МУП) хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакына бәйлелеген билгеләү.

1.2. МУП җитәкчесенең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәт хакы вазифа окладыннан, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы өстәмәләрдән, МУП җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын премияләү турындагы нигезләмәдә билгеләнгән стимуллаштыручы характердагы түләүләрдән һәм әлеге Нигезләмәненң 1.5 пунктта күрсәтелгән һәм/яки хезмәт килешүе белән билгеләнгән башка түләүләрдән тора.

1.3.Җитәкченең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның уртача айлык хезмәт хакы күләме финанс тәэмин итүнең барлык чыганаклары хисабына формалашып, календарь елына исәпләнелә торган муниципаль унитар предприятие җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының уртача айлык хезмәт хакы нисбәтеннән һәм әлеге предприятиеләр хезмәткәрләренең уртача айлык эш хакына карата (җитәкчеләр, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлар исәбеннән башка) билгеләнгән чик дәрәҗәсеннән артмаска тиеш.

1.4.Муниципаль унитар предприятие җитәкчесенең, аның урынбасарының һәм баш бухгалтерның уртача айлык хезмәт хакы турында белешмәләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 349.5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль

районының рәсми сайтында (алга таба-районның рәсми сайты) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән расланган тәртиптә урнаштырылырга тиеш.

1.5.Әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларда уртача айлык хезмәт хакын билгеләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләү тәртибенең үзенчәлекләре турында» 24.12.2007 ел, №922 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.6.Гражданга бәйле булмаган хәлләр буенча социаль ярдәмгә мохтаҗ затларга әлеге Нигезләмәдә каралмаган бүтән түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексында һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

## II.МУП җитәкченең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерының хезмәт окладлары күләмен билгеләү тәртибе

2.1.Җитәкченең вазыйфа окладны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) тарафыннан билгеләнә һәм МУП хезмәткәрләренең исемлек составының (җитәкченең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәт хакын исәпкә алмыйча) уртача айлык хезмәт хакын хезмәткә түләү коэффициентына тапкырлау юлы белән билгеләнә.

2.2.Муниципаль унитар предприятиеләрнең исемлек составы хезмәткәрләренең уртача айлык хезмәт хакы соңгы финанс хисабы елына, барлык финанслау чыганаклары исәбенә башкарыла торган түләүләрне исәпкә алып исәпләнә.

2.3.Хезмәт хакы коэффициенты түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып билгеләнә:

а) финанс нәтиҗәләре турындагы хисап мәгълүматлары буенча муниципаль унитар предприятиенең соңгы хисап финанс елы өчен кереме күләменә карап (К1 коэффициенты):

| коэффициент К1 | 0,5 | 0,55 | 0,6 | 0,65 | 0,7 | 0,75 | 0,8 | 0,85 | 0,9 | 0,95 | 1 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Керем (млн.сум) | 2 кимрәк | 2 дән 10га | 10 нан 50 гә | 50 дән 100гә | 100 дән 300 гә | 300 дән 500 гә | 500 дән 1000гә | 1000нән 15 000гә | 15 000 нән 30 000гә | 30 000 нән 50 000 гә | 50 000 артык |

б) муниципаль унитар предприятие җитәкчесенең хисап мәгълүматлары буенча соңгы хисап финанс елы өчен МУП хезмәткәрләренең фактик санына карап (К2 коэффициенты):

| Коэффициент К2 | 0,5 | 0,55 | 0,6 | 0,65 | 0,7 | 0,75 | 0,8 | 0,85 | 0,9 | 0,95 | 1 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| Исемлектәге кеше саны | 10 ким | 10 нан 50 гә | 50 дән 100гә | 100 дән 500 гә | 500дән 800 гә | 800 дән 1000гә | 1000 нән 1500гә | 1500 дән 2000 гә | 2000 нән 3000гә | 3000 нән 4000гә | 4000артык |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

2.4.Муниципаль унитар оешманың хезмәткәрләре исемлек составына җитәкче, аның урынбасарлары һәм баш бухгалтердан кала барлык МУП хезмәткәрләре дә керә. Предприятие хезмәткәрләренең факттагы санын (уртача айлык хезмәт хакын исәпләү өчен кабул ителә торган) алу өчен исемлек составындагы хезмәткәрләр санынннан йөклелек һәм бала тудыру буенча отпускларда, отпускларда, яңа туган баланы (балаларны) уллыкка алу (кызлыкка алу) белән бәйле, отпускларда, бу вазыйфаны биләү өчен өч яшькә җиткәнче баланы карау буенча хезмәт хакын саклап калмыйча, отпускларда булган хезмәткәрләр, әгәр ашыгыч хезмәт килешүе нигезендә хезмәткәр кабул ителмәгән булса, төшереп калдырыла.

2.5.К1 һәм К2 коэффициентлары суммасы хезмәт өчен түләү коэффициентын тәшкил итә.

2.6.Муниципаль унитар предприятие яңадан төзелгән очракта, беренче елда җитәкченең вазыйфаи оклады Федераль дәүләт статистикасы хезмәте мәгълүматлары нигезендә тармакның тиешле оешмасы буенча уртача айлык хезмәт хакының өч тапкыр күләмен тәшкил итә.

2.7.Муниципаль унитар предприятие җитәкчесе урынбасарларының һәм баш бухгалтерның хезмәт окладының күләмен һәм аңа өстәмәләрнең күләмен билгеләү тәртибе, әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктында билгеләнгән чикләүләрне исәпкә алып, МУПның эчке документлары белән раслана.

## III. Аерым категория МУП җитәкчеләрнең вазыйфаи окладларын исәпләп чыгару буенча махсус нигезләмәләр

3.1. МУП зыянга эшләгән очракта, вазифаи оклады әлеге Нигезләмәнең 2.1 - 2.5 пунктлары нигезендә исәпләнгән җитәкченең вазыйфаи оклады , соңгы финанс хисап елы (финанс нәтиҗәләре турындагы хисап мәгълүматлары буенча) һәм югалту барлыкка килү чорына бәйле рәвештә билгеләнә:

а) узган хисап елында МУП зыянга эшләгән очракта:

| **Отношение суммы убытка к выручке** | **Процент должностного оклада** |
|---|---|
| до 5% | 95 |
| от 5,01% до 10% | 90 |
| от 10,01% до 20% | 85 |
| свыше 20,01% | 50 |

б) МУП ике һәм аннан да күбрәк хисап еллары дәвамында зыянга эшләсә:

| **Отношение суммы убытка к выручке** | **Процент должностного оклада** |
|---|---|

| | |
|---|---|
| до 5% | 85 |
| от 5,01% до 10% | 80 |
| от 10,01% до 20% | 75 |
| свыше 20,01% | 50. |

3.2.Зыянга эшләүче муниципаль унитар предприятие җитәкчесенә вазыйфаи окладны билгеләгәндә, аның эшчәнлегенең беренче елында (билгеләнгән көннән) әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункт нормасы кулланылмый.

3.3.Әгәр инде булган мәйданнарның 50 проценттан артыгы, шулай ук МУП җиһазлары өченче затларга арендага тапшырылган икән, җитәкченең вазыйфаи окладының зурлыгы тариф челтәре нигезендә билгеләнә.

## IV.Җитәкченең вазифаи окладына компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр

4.1.Компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы өстәмәләр әлеге нигезләмәнең 2.1-2.5 пунктлары нигезендә исәпләнгән җитәкченең вазыйфа окладына процентларда билгеләнә.

4.2.Җитәкченең вазыйфа окладына компенсация һәм кызыксындыру характерындагы өстәмәләр күләме Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге (алга таба-Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге) һәм/яки Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан (килештерү буенча) (алга таба – мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) тарафыннан тәкъдим ителә. Өстәмәләрнең ахыргы күләме Башкарма комитет тарафыннан Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге, Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тәкъдимнәре һәм МУПның финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен анализлау нигезендә раслана.

4.3.Компенсация һәм кызыксындыру характерындагы өстәмәләрнең гомуми күләме әлеге Нигезләмәнең 2.1 — 2.5 пунктлары нигезендә исәпләнгән вазыйфа окладының 300 процентыннан артмаска тиеш.

4.4.Компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне тормышка ашыру өчен акча чираттагы финанс елына хезмәткә түләү фондын планлаштырганда карала.

4.5.Җитәкчегә компенсация характерындагы түбәндәге өстәмәләр билгеләнергә мөмкин:

4.5.1.дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр белән эшләү өчен (тиешле рөхсәт булганда) – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән күләме һәм тәртибе буенча;

4.5.2.махсус режим, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен- хезмәт хакының 10-30 проценты.

4.6.Җитәкчегә стимуллаштыручы характердагы түбәндәге өстәмәләр бирелергә мөмкин:

4.6.1. җитештерү процессына яңа технологияләр һәм инновацияләр

кертү өчен-50 процентка кадәр;

4.6.2. предприятие эшчәнлегенең яңа рентабельле төрләрен үстерү өчен-50 процентка кадәр;

4.6.3. аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен-100 процентка кадәр;

4.6.4. интенсивлык һәм югары эш нәтиҗәләре өчен-100 процентка кадәр;

4.6.5. тармак өстәмәсе-50 процентка кадәр;

4.6.6. филиаллар һәм структур бүлекчәләр булган өчен-100 процентка кадәр (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясен колачлауга карап);

4.6.7. узган ел җитештерү травматизмы булмаган өчен – 10 процент;

4.6.8. җитәкче вазыйфада өзлексез эш стажы өчен:

| **Эш Стажы** | **Әлеге нигезләмәнең 2.1 -2.6 пунктлары нигезендә исәпләнгән вазыйфаи окладка өстәмәнең күләме, процентларда** |
|---|---|
| 1 дән 5 елга кадәр | 10 |
| 5 тән 10 елга кадәр | 20 |
| 10 елдан артык | 30 |

## V. Җитәкче хезмәт хакы һәм аңа өстәмәләр күләмен үзгәртү тәртибе

5.1.Җитәкченең вазыйфаи окладының күләме чираттагы финанс елы нәтиҗәләре буенча үзгәртелергә мөмкин, бу күрсәткечләр нигезендә вазыйфаи окладны исәпләү гамәлгә ашырыла (МУП җитәкчесенең тиешле ел өчен хисабы мәгълүматлары буенча).

5.2. Вазыйфаи окладка өстәмәләрнең күләме Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы тәкъдимнәре белән, МУПның финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләрен исәпкә алып үзгәртелергә мөмкин. Җитәкче вазифа окладына өстәмәләрне үзгәртү турында соңгы карарны Башкарма комитет кабул итә.

5.3.Җитәкченең вазифаи окладының һәм аңа өстәмәләрнең күләмнәрен үзгәртү җитәкче белән хезмәт шартнамәсенә өстәмә килешү төзү яки хезмәт окладын үзгәртү турында карар кабул ителгән көнгә гамәлдәге хезмәт килешүенең гамәлдә булу срогы чыккан очракта хезмәт килешүе төзү юлы белән башкарыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 1 февралендәге 16 пи номерлы карары белән расланган

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын премияләү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын премияләү турындагы әлеге нигезләмә (алга таба-нигезләмә) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын һәм баш бухгалтерларын премияләү тәртибен билгели.

1.2. Җитәкчегә, аның урынбасарларына һәм баш бухгалтерына премияләр МУП эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә ирешүдә, вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намуслы башкаруда стимуллаштыру, җитәкченең, аның урынбасарларының һәм баш бухгалтерның кабул ителгән карарлар өчен җаваплылыгын арттыру максатында түләнә.

1.3.Җитәкчегә, аның урынбасарларына һәм баш бухгалтерга премияләр муниципаль унитар предприятие карамагында калган чиста табыш хисабына башкарыла.

1.4.Җитәкчегә карата МУП хезмәткәрләрен премияләү белән бәйле оешманың нигезләмәләре, килешүләре яки башка локаль эчке норматив актлары (документлары) кулланылмый.

1.5.Җитәкченең, гамәлдәге законнар белән гарантияләнгән түләүләрдән тыш, әлеге Нигезләмәдә һәм хезмәт шартнамәсендә каралмаган вазыйфаи бурычларын үтәүгә бәйле МУП акчаларыннан түләүләр алырга хокукы юк.

1.6.Җитәкчене премияләү предприятие хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча барлык йөкләмәләрне гарантияләнгән үтәү шарты белән генә башкарыла ала.

## II.Җитәкчегә премия төрләре

2.1.Җитәкче өчен түбәндәге премияләр каралган:

2.1.1.Квартал (1, 2, 3 һәм 4 квартал)эш нәтиҗәләре буенча премия;

2.1.2.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба-Башкарма комитет) тарафыннан расланган эшчәнлек нәтиҗәлелеге индикаторларын башкарган өчен премия ;

2.1.3.МУПның төп эшчәнлеге белән бәйле ярышларда, конкурсларда һ. б. призлы урыннар өчен премия;

2.1.4.Тармак премиясе (елына ике тапкырдан артык түләнергә тиеш түгел).

2.2.Җитәкчегә карата премияләрнең башка төрләре кулланылмый.

2.3.Барлык премияләр дә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге һәм мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба-мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы) белән язма килешү буенча башкарыла.

2.4.Хисап чорында МУПның финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсе зыян күргән очракта, җитәкчегә премияләр түләнми.

2.5.Календарь елы өчен премияләрнең гомуми күләме җитәкченең хезмәт окладының 300 процентыннан артмаска тиеш.КАЛДЫМ

2.6.Башкарма комитетның территориаль үсеш бүлеге һәм мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тарафыннан МУП җитәкчесенә әлеге Нигезләмәнең 2.1.1– 2.1.4. пунктларында билгеләнгән премияләрне түләү мәсьәләсен килештерү.  иң чик дәрәҗәсе муниципаль унитар предприятие җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары һәм календарь елына исәп-хисап ясала торган уртача айлык хезмәт хакы нисбәтенең һәм Башкарма комитет раслаган әлеге предприятиеләр хезмәткәрләренең (җитәкчеләр, аларның урынбасарлары һәм баш бухгалтерлар исәпкә алмыйча) уртача хезмәт хакының нисбәтен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

## III.Башкарма комитет раслаган эшчәнлек күрсәткечләрен үтәгән өчен премия бирү

3.1.Башкарма комитет раслаган эшчәнлек нәтиҗәлелеге индикаторларын (алга таба – индикаторлар) башкарган өчен җитәкчеләргә премия тиешле чорда МУП эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген характерлаучы башкарылган күрсәткечләр саныннан чыгып башкарыла.

3.2.Финанс елы нәтиҗәләре буенча, барлык индикаторларны үтәгән (арттырып үтәгән) очракта җитәкчегә бер вазыйфа окладының (стимуллаштыручы һәм компенсация характерындагы өстәмәләрне исәпкә алмыйча) күләмендә премия түләнә.

3.3.Биш яки аннан да күбрәк индикатор җитәкче тарафыннан 20 процентан артыграк үтәлгән очракта, премия ике вазифа оклады күләмендә түләнә (стимуллаштыручы һәм компенсация характерындагы өстәмәләрне исәпкә алмыйча).

3.4.Бер яки берничә (биштән артык түгел) күрсәткеч үтәлмәгән очракта, премия күләме түбәндәгечә исәпләнә:

а) үтәлмәгән күрсәткечләрнең һәрберсе буенча кимү коэффициенты билгеләнә:

| №п/п | Күрсәткеч атамасы | Билгеләнгән дәрәҗәдән индикаторны үтәү, процент | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 99.9 дән 95кә | 94,9 дән 80гә | 79,9 дан 70кә | 69,9 дан 60ка | 69,9 дан 50гә | 50ким |
| 1 | | 0,01 | 0,03 | 0,06 | 0,08 | 0,1 | 0,2; |
| . . . | | | | | | | |
| п | | | | | | | |

б)башкарылмаган индикаторлар буенча кимү коэффициентлары кушыла - кимүнең йомгак коэффициенты (К);

в) бер оклад күләме (стимуллаштыру һәм компенсация характерындагы өстәмәләрне исәпкә алмыйча) аермага тапкырлана (1 - К) - премиянең йомгак суммасы, ягъни.:

Премия = Оклад * (1-К),

монда К - кимүнең йомгаклау коэффициенты суммасы.

3.5.Җитәкче биш яки аннан да күбрәк индикаторны үтәмәгән очракта (үтәлмәү процентына карамастан) премия түләнми.

3.6.Премия күрсәткечләрне үтәү нәтиҗәләре буенча елга бер тапкыр түләнә).

IV.Җитәкчене премиядән мәхрүм итү шартлары (депремирование)

4.1Җитәкчегә түбәндәге очракларда премия түләнми яки премия күләме кими:

4.1.1.3 айдан артык срогы чыккан 100 000 (йөз мең) сумнан артык кредитор бурыч булуы-барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.2.муниципаль унитар предприятиеләрнең чиста табыш өлешен күчерү буенча бурычлары булу яки срокларын (бер көннән артык) бозу – барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.3.җитәкченең хезмәт килешүе шартларын бозуы-барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.4.Башкарма комитетның законлы таләпләрен үтәмәү-барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.5.финанс-хуҗалык дисциплинасын тупас бозу, шулай ук муниципаль унитар предприятиегә матди зыян китерү - барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.6.МУП хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча кичектерелгән бурычлар булу – барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.7. Тикшерүче органнарның финанс-хуҗалык эшчәнлеген алып бару, шулай ук МУП мөлкәтен файдалану һәм сакланышын тәэмин итү буеча искәртүләре булу – барлык төр премияләрдән мәхрүм итү;

4.1.8.бухгалтер хисаплылыгын һәм җитәкченең билгеләнгән формалар буенча отчетларын тапшыру тәртибен һәм срокларын бозу – премия күләме 50 процентка кими;

4.1.9.Башкарма комитет соравы буенча мәгълүмат тапшыру срокларын бозу-премия күләме 50 процентка кими;

4.1.10. түләтү мөмкин булмаган дебиторлык бурычын гамәлдән чыгару, әгәр аны түләттерү буенча барлык кирәкле процедуралар тиешле күләмдә башкарылмаган булса (суд эше булмау) – премия күләме 50 процентка кими.

## V. Җитәкче һәм баш хисапчы урынбасарларын премияләү тәртибе

Муниципаль унитар предприятие җитәкчесе һәм баш бухгалтеры урынбасарларына премия МУП хезмәткәрләрен премияләү тәртибен билгели торган МУПның эчке норматив актлары (документлары) нигезендә башкарыла.